ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
"АЕРЫМ ПРЕДМЕТЛАР ТИРӘНТЕН ӨЙРӘНЕЛӘ ТОРГАН
2НЧЕ АЛЕКСЕЕВСК УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ"
МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ УЧРЕЖДЕНИЯСЕ

| «КАРАЛДЫ» | «КИЛЕШЕНДЕ» | «РАСЛАНДЫ» |
|---|---|---|
| Методик берләшмә җитәкчесе<br>__________И.Х.Замалиева<br>МБ утырышы беркетмәсе<br>№1 «25» август 2016 ел | Директор урынбасары<br>________Л.Р.Ягудина<br><br>«27» август 2016 ел | Мәктәп директоры<br>__________Л.Н.Липлянина<br>Педагогик совет беркетмәсе<br>233 нче номерлы боерык белән гамәлгә кертелде.<br>31 нче август 2016 ел |

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Сөнгатуллина Флюра Сафуат кызының
7«А» сыйныфы өчен татар әдәбиятыннан
эш программасы

Педагогик киңәшмә
утырышында каралды.
Беркетмә №1
31 август 2016 ел

2016– 2017 уку елы

## Татар әдәбиятын  укыту - тематик планлаштыру

Сыйныф: 7-,а татар төркеме

Укытучы: Сунгатуллина Флюра Сафуатовна.

Сәгатьләр саны :35

Еллык сәгатьләр саны: 35  ;    атнага 1 сәгать.

Планлаштыру нигезе:

**Программа:** Рус  телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар әдәбиятын  укыту программасы (татар балалары өчен),  1- 11 нче сыйныфлар. – Казан: Мәгариф, 2011.

**Дәреслек:** Татар әдәбияты 7 сыйныф:рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы(татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) Ә. Н Нәҗипова Л. Ш Исхакова  (Ф.Г. Галимуллин  редакциясендә).- Казан: Татар китап нәшрияте.,2015.

**Укыту предметын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре**

1.Россия Федерациясе Конституциясе 26 ст.
2.Татарстан Республикасы Конституциясе 8 ст.
3. « Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль Законы №273-ФЗ (үзгәрешләр 03.02.2014 , №11-ФЗ, 15-ФЗ);
4. «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законы ,8 ст., №68-ЗРТ, 22 июль 2013 ел
5. «Россия Федерациясенең халыклары телләре турында» Законы, 24.07.98, №126-ФЗ;
6. Россия Федерациясенең милли мәгариф сәясәте концепциясе, 03.08.2006, №201;
7. «Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» Татарстан Республикасы Законы , 08.07.1992 №1560-XII (ред. 03.03.2012
8.“2014-2020 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт программасы”
9.”Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары өчен төп белем бирү программаларының эчтәлеген проектлау буенча методик тәкъдимнәрен раслау турында” №1063/15,19.08.15.
10. “Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен укыту программасы (татар балалары өчен; 1-11нче сыйныфлар)” Ул “Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар (1-11 нче сыйныфлар)” да урын алган. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы. Казан: Татарстан, 2011.
11.Приказ МО и Н РТ от 9 июня 2012 года № 4154/12 «Об утверждении базисного и примерных учебных планов для образовательных учреждений Республики Татарстан, реализующих программы начального общего и основного общего образования»
12. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының “Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 2 нче Алексеевск урта гомуми белем бирү мәктәбе” нең төп гомуми белем бирүнең төп белем бирү программасы.
13. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының “Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 2 нче Алексеевск урта гомуми белем бирү мәктәбе” нең 2016-2017 нчы уку елына укыту планы ( педсовет, беркетмә №1, 31 август 2016 ел)

Татар әдәбиятының эш программасы өч өлештән тора: аңлатма язуыннан, төп бүлекләрне, белем һәм күнекмәләрне үз эченә алган программаның эчтәлегеннән, укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләреннән.

**Эш программасының эчтәлеге**

***Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына әдәбият укытуның төп максаты һәм бурычлары***

- матур әдәбият текстларын форма һәм эчтәлек берлегендә аңлап кабул итү;
- төп әдәби-тарихи мәгълүматларны һәм әдәби теоретик төшенчәләрне белү;
- балаларны татар әдәбияты, халык авыз иҗаты, татар халкының җыр-музыкасы, театры, сынлы сәнгате белән таныштыру, күренекле язучылар һәм аларның әсәрләрен үзләштерүләренә ирешү;
- укучыларның телдән һәм язма сөйләмнәрен үстерү;
- әдәби әсәрне уку һәм анализлау;
- халык тарихын, мирасын өйрәнү аша Ватанга, халыкка, туган телгә мәхәббәт, олыларга, кечеләргә һәм, гомумән, кешегә ихтирам, мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек тәрбияләү.

**7 нчы сыйныфны тәмамлаган татар балалары үзләштерергә тиешле белем-күнекмәләр**

- өйрәнгән әдәби әсәрнең эчтәлеген белү;
- классик әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларының төп фактларын истә калдыру;
- әдәби текстны кабул итү һәм анализлау, укыган буенча план төзү;
- геройларга характеристика бирү;
- әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыру, автор позициясен ачыклау;
- укыганга үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерү, әсәрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку;
-җырлар һәм аларның төрләрен аера белү;
-хикәя,фантастик хикәяне аера белү;
-шигырь һәм поэманың үзенчәлекләрен белү;
-уңай герой,лирик герой төшенчәләрен аера белү;
-әдәби әсәрләрдән сурәтләү чараларын таба белү;
-милли орнаментларны аера белү.

**Укуны бәяләү.**

Укучыларның 1 минутка уку тизлеге түбәндәгечә бәяләнә:

| Класслар | Икенче яртыеллыкта | |
|---|---|---|
| | Иҗек саны | Сүз саны |
| 7 | 150-200 | 85-95 |

**Искәрмә.** Эчтән уку тизлеге, кычкырып уку белән чагыштырганда, 5-7 нче класларда – 30-40 процентка, ә 8-9 нчы класларда 40-50 процентка югарырак була.

**Әдәби әсәрләрне танып-белү буенча төп эшчәнлек төрләре:**

- Төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне аңлап һәм иҗади уку;
- сәнгатьле уку;
- кабатлап сөйләүнең төрле төрләре (тулы итеп, кыскача, сайлап, аңлатмалар белән, иҗади бирем белән);
- шигъри текстларны яисә чәчмә әсәрдән өзекләрне яттан өйрәнү;
- әсәрләрне анализлау һәм шәрехләү;
- план төзү һәм әсәрләр турында бәяләмә (отзыв) язу;
- сочинение элементлары белән изложение язу;
- әдәби әсәрләр буенча һәм тормыштан алган фикер-карашларга, хис-кичерешләргә нигезләнеп сочинение язу;
- тема, проблема, жанр уртаклыклары нигезендә татар һәм рус әдәбиятындагы әсәрләрне чагыштырып бәяләү;
- рус телендәге әдәби текстларны татарчага һәм киресенчә тәрҗемә итү.

**Укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр:**

- сүз сәнгатенең образлы табигате;
- өйрәнгән әдәби әсәрнең эчтәлеге;
- классик әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларының төп фактлары;
- өйрәнгән әдәби-теоретик төшенчәләр;
- әдәби текстны кабул итү һәм анализлау;
- әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып чыгару, укыган буенча тезислар һәм план төзү;
- әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын ачыклау;
- укыган әсәрнең темасын, проблемасын, идеясен билгеләү;
- геройларга характеристика бирү;
- сюжет, композиция үзенчәлекләрен, махсус сурәтләү чараларының ролен ачу;
- әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыру;
- укыганга үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерү;
- әсәрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку;
- кабатлап сөйләүнең төрләреннән файдалану;
- өйрәнелгән әсәргә бәйле телдән һәм язмача фикерләрне белдерү;
- укыган әсәр буенча фикер алышуда катнашу, фикерләреңне дәлилле белү;
- укыган әсәрләргә бәяләмә (отзыв) язу;
- татар әдәби теленең нормаларына нигезләнеп, кирәкле темага телдән һәм язмача бәйләнешле текст төзү;

- эстетик зәвыкка туры килә торган әдәби әсәрләрне сайлау һәм аларны бәяләү;
- аерым автор, аның әсәре, гомумән әдәбият турында кирәкле мәгълүматны белешмә әдәбият, вакытлы матбугат, Интернет чаралары һ.б. аша эзләү.

**Әдәбият дәфтәренә таләпләр**

Әдәбият дәфтәрендә һәр уку елы дәвамында түбәндәге төп язмалар була:

1) планнар
2) эчтәлекне хикәяләп язу
3) цитаталар (күчереп язу)
4) аңлатмалар (сүз һәм төшенчәләргә)
5) фикер язмалары (үз фикереңне язып кую)
6) укучы үзе иҗат иткән әдәби әсәрләр (хикәяләр, шигырьләр, мәзәкләр, сценарийлар һ.б
7) халык авыз иҗатыннан җирле материаллар

Әдәбият дәфтәрендә бары тик программа материалын үзләштерүгә һәм аны язып бирә белергә өйрәтә торган язмалар гына булырга тиеш. Язма эшләр сочинение таләпләре белән бәяләнә.

Әдәбияттан белем дәрәҗәсен бәяләү соңгы чиктә сочинение яздыру белән кылынса да, өлгереш билгеләре чыгарган вакытта аның белән генә чикләнмичә, уку, сөйләү, телдән җавап бирү дә исәпкә алына.

**Сочинениене бәяләү**

1. Язманың эчтәлеге темага тулысынча туры килсә, фактик ялгышлары булмаса, бай телдә, образлы итеп язылса, стиль бердәмлеге сакланса, «5» ле куела. (Бер орфографик яисә ике пунктуацион (грамматик) хата булырга мөмкин.)
2. Язманың эчтәлеге нигездә темага туры килсә, хикәяләүдә зур булмаган ялгышлыклар күзәтелсә, бер-ике фактик хата җибәрелсә, теле бай, стиль ягы камил булып, ике орфографик, өч пунктуацион (грамматик) яисә бер-ике сөйләм ялгышы булса, «4» ле куела.
3. Эчтәлекне бирүдә җитди ялгышлар, аерым фактик төгәлсезлекләр булса, хикәяләүдә эзлеклелек югалса, сүзлек байлыгы ярлы булса, стиль бердәмлеге дөрес сакланмаган җөмләләр очраса, өч орфографик, дүрт пунктуацион (грамматик) яисә өч-дүрт сөйләм хатасы булса, «3» ле куела.
4. Язма темага туры килмичә, фактик төгәлсезлекләр күп булып, план нигезендә язылмаса, сүзлек байлыгы бик ярлы булса, текст кыска һәм бер типтагы җөмләләрдән торып, сүзләр дөрес кулланылмаса, стиль бердәмлеге сакланмаса, биш орфографик, сигез пунктуацион (грамматик) яисә дүрт—алты сөйләм хатасы булса, «2» ле куела.

**Укуга карата төп таләп – сәнгатьле уку.**

<u>Уку материалы:</u>

1. Укучы үзе язган текст яки сочинение.
2. Әдәби әсәрдән, публицистик һәм фәнни хезмәттән өзек.

<u>Материалның күләме:</u>

Һәр класс өчен билгеләнгән сочинение күләме икеләтә алына.

<u>Материалны сайлап алу:</u>

1. Укучы үзе сайлый, үзе теләгән текстны укый.
2. Укытучы күрсәтмә бирә.

<u>Укуны әдәбият фәне буенча бәяләү өчен таләпләр:</u>

1. Уку тел (грамматика) фәне буенча уңай билге куярлык булсын.
2. Сәнгатьле яисә логик сәнгатьле (текстның характерыннан чыгып) башкарылсын.
3. Уку интонациясен бөтен текстка һәм аның аерым өлешләренә карата укучы аңлатып бирә белсен.

И с к ә р м ә. Уку интонациясен аңлатканда:
1. V – VII классларда интонациянең текст эчтәлегенә карата булган ягын аңлату җитә (ягъни объектив эчтәлектән чыгып).
2. VIII класста авторның тексттагы эчтәлеккә мөнәсәбәтен чагылдыру дәрәҗәсенә бәйләп аңлату да таләп ителә.
3. IX - XI классларда укучы, болар өстенә, текст эчтәлегенә үзенең мөнәсәбәтен, тыңлаучыларга ничек тәэсир итәргә, аларда нинди хисләр уятырга теләгәнлеген дә аңлатырга тиеш.

Соңгы ике таләптән берсенең үтәлмәве тел буенча куелган билгене – бер баллга, икесенең дә кимчелекле үтәлүе билгене ике баллга киметә. Икесе дә бөтенләй үтәлмәгән булса, әдәбияттан “2”ле куела.

**7сыйныф (17 әсәр)**

Татар әдипләренең әсәрләре:

Г. Тукай “Шүрәле”, “Туган авыл”;

Г.Ибраһимов “Табигать балалары”.;

Һ. Такташ “Ак чәчәкләр”

Г.Кутуй “Рәссам” ”;

Г. Бәширов “Менә сиңа мә!”;

И. Гази “Йолдызлы малай”(өзек);

М. Мәһдиев “Без кырык беренче лл балалары”(өзек);

Ә. Еники “Кем җырлады””Туган туфрак”

С.Хәким”Торыгыз, Мусалар”Татарлар елмаеп үлделәр”

Н. Нәҗми “Татар теле”

Г.Зәйнәшева “Туган җирем -Татарстан

Хәзерге заман әдәбияты

Туфан Миннуллин “ Монда тудык ,монда үстек.

М. Галиев “Нигез”

Әдәбиятлар бәйләнеше.

Иван Крылов “Аккош,Чуртан һәм Кысла”

“Бүре белән бәрән”.

Александр Пушкин

“Җырчы” “Кышкы кич”

**Татар әдәбиятыннан календарь –тематик планлаштыру**
**7 а сыйныфы**

| № | Тема | Эшчәнлек төре | Үтәлү вакыты |
|---|---|---|---|
| 1. | Халык аваз иҗаты.Дастан. Идегәй. | Әңгәмә,дәреслек , дәфтәр белән эшләү. | 2.09 |
| 2. | Г.Тукай. Милли моңнар” “Кышкы кич” шиг. | Сәнгатьле уку,сорауларга җавап эзләү. | 9.09 |
| 3. | Г.Ибраһимов. Тормыш юлы.иҗаты. | Төркемнәрлә биремнәр үтәү, дәреслек бн эш. | 16.09 |
| 4 | Г.Ибраһимов. “Табигать балалары”.хикәясе. | Чылбыр буенча сән.уку,яңа сүзләрне уку,язу. | 23.09 |
| 5 | Һ.Такташ.”Ак чәчәкләр” “Алсу” поэмасы. | Сәнгатьле уку, сорауларга җавап бирү. | 30.09 |
| 6. | Б.С.Ү. “Дустың турында хикәя язу”. | Б.С.Ү.сүзлекләр белән эшләү. | 7.10 |
| 7. | Г.Кутуй.Биографик белешмә.”Рәссам” | Яңа сүзләрне өйрәнү, сән.уку, | 14.10 |
| 8. | Ф.Кәрим.иҗаты. “Бездә яздыр””Сөйләр сүзләр бик күп алар” шиг. | Сәнгатьле уку,сораулар,биремнәр үтәү. | 21.10 |
| 9. | ХТуфан. Иҗаты. “Киек казлар”. “Кайсыгызның кулы җылы?”шиг. | През. карау,төркемнәрдә фикер алышу. | 28.10 |
| 10. | Дәрестән тыш уку. Г.Гөбәй.”Ләйсән яңгыр” | Д.т.уку.сәнгатьле уку, сүзлек белән эш. | 11.11 |
| 12. | Г.Бәширов. Иҗаты.”Менә сиңа мә”! | Дәреслек,дәфтәр белән эшләү, биремнәр үтәү. | 18.11 |
| 13. | И.Гази.Иҗат юлы.”Йолдызлы малай” | Дәреслек белән эшләү, төркемнәрдә эш. | 25.11 |
| 14. | Инша.”Мин Ильгизәр урынында нәрсә эшләр идем?” | Инша. | 2.12 |
| 15. | Ә.Еники. Тормыш юлы,иҗаты.”Кем җырлады?”хикәясе. | План төзү,чылбыр буенча уку. | 9.12 |
| 16. | Ә Еники “Туган туфрак.” хикәясе. | Сәнг. уку, фикер алышу,сораулар ,биремнәр үтәү. | 16.12 |
| 17. | С.Хәким.иҗаты.”Торыгыз Мусалар.”Татарлар елмаеп үлделәр.” | През.карау, сән. уку, биремнәр үтәү. | 23.12 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 18. | “Татарлар елмаеп үлделәр”.инша. | Инша. | 13.01 |
| 19. | Н.Нәҗми.”Татар теле”шиг. | Сәнгатьле уку, сораулар,бирем нәр үтәү. | 20.01 |
| 20. | Г.Зәйнашеав.”Туган җиркм.- Татарстан.” Шиг. | Дәреслек белән эшләү, сән. уку .сраулар биремнәр . үтәү. | 27.01 |
| 21. | М.Мәһдиев.”Без –кырык беренче ел балалары.”. | Дәреслек белән эшләү, сән. уку. | 3.02 |
| 22. | Әсәрдә сугыш чоры балалары. | Чылбыр буенча.сән. уку, | 10.02 |
| 23. | Т.Миңнуллин.иҗаты.”Монда тудык,монда үстек. | През. карау,сораулар ,биремнәр эшләү. | 17.02 |
| 24. | Инша. Монда тудык, монда үстек”. | Инша. | 24.02 |
| 25. | Дәрестән тыш уку. | Д.т.уку | 3.03 |
| 26. | М.Галиев.Иҗат юлы. | Дәреслек ,дәфтәр белән эш. | 10.03 |
| 27. | М.Галиев. “Нигез”.повесте. | Сән. уку, сорааулар,бирем нәр үтәү. | 17.03 |
| 28 . | “Нигез “повесте. | Сән. уку,эчтәлек сөйләү, | 31.03 |
| 29. | Әсәрдә “Өянке”образы. | Төркемнәрдә эшләү, дәфтәр белән эш. | 14.04 |
| 30. | И.Крылов.иҗаты.”Аккош ,Чуртан һәм Кысла” мәсәле.”Бүре белән бәрән” | Сән. уку, сораулар һәм биремнәр. | 21.04 |
| 31. | А. Пушкин.иҗаты”Җырчы” “Кышкы кич” шиг. | През. ясау,сән. уку,фикер алышу. | 20.04 |
| 32 | Б.С.Ү Республикабыздагы истәлекле урыннар. | През. ясау, карау,әңгәмә. | 5.05 |
| 33. | Татарстан минем горурлыгым.Б.С.Ү | Рәсем өстендә эшләү, төркемнәрдә эшләү. | 12.05 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 34. | Дәрестән тыш уку. Г.Кашапов.”Киек каз юлы”. | Хикәяне уку, эчтәлекне аңлау. | 19.05 |
| 35. | Гомумиләштереп кабатлау. | Дәреслек, дәфтәр белән эшләү. | 26.05 |

Пронумеровано прошнуровано
И скреплено печатью
12 (двенадцать) листов
Учитель татарского языка и
Литературы

Алексеевская
средняя
общеобразовательна
школа №2
с углублённым изучением
отдельных предметов»
ИНН 1605001185